ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

19 апрель 2024 ел

**КАРАР**

№ 2474

«Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын конкурста сайлап алу турында

Яр Чаллы шәһәрендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 елның 27 августындагы 616 номерлы Карары белән билгеләнгән «сәнәгать (индустриаль) паркы» төренә кертү таләпләре (критерийлары), Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Үсеш» сәнәгать паркы турында» 2012 елның 30 ноябрендәге 8759 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) «Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын конкурста сайлап алуны үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) «Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе составын, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитет Карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү турында» 2015 елның 8 октябрендәге 5711 номерлы;

2) «Башкарма комитетның «Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү турында» 2015 елның 8 октябрендәге 5711 номерлы Карары белән расланган «Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 11 июлендәге 4109 номерлы;

3) «Башкарма комитетның «Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү турында» 2015 елның 8 октябрендәге 5711 номерлы Карары белән расланган «Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 10 сентябрендәге 4592 номерлы;

4) «Башкарма комитетның «Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү турында» 2015 елның 8 октябрендәге

5711 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 декабрендәге 7134 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 19 апрелендәге
2474 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын
конкурста сайлап алуны үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәренең «Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын конкурста сайлап алуны үткәрү турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) резидентларны һәм «Үсеш» сәнәгать паркында (алга таба – Сәнәгать паркы) тормышка ашырыла торган инвестиция проектларын конкурста сайлап алуны оештыру һәм үткәрү тәртибен һәм төп шартларын билгели.

2. Яр Чаллы шәһәренең «Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын конкурста сайлап алу (алга таба – конкурста сайлап алу) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2016 елның 9 ноябрендәге 11/6 номерлы Карары нигезендә, ташламалы шартларда Сәнәгать паркы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен юридик затларны яки шәхси эшмәкәрләрне сайлап алу максатында үткәрелә.

3. Конкурста сайлап алуның оештыручысы булып Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе (алга таба - оештыручы) тора.

4. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган терминнар һәм билгеләмәләр:

1) сәнәгать паркы – производство урнаштыру, кече һәм урта производстволарның нәтиҗәле эше өчен шартлар тудыру мөмкинлеге бирә торган инфраструктуралы күчемсез милек объектларының территориаль аерымланган комплексы;

2) сәнәгать паркы резиденты – гамәлдәге законнар нигезендә теркәлгән һәм үз эшчәнлекләрен Яр Чаллы шәһәре территориясендә гамәлгә ашыручы, сәнәгать паркының күчемсез милек объектларыннан, инфраструктурасыннан файдаланучы һәм аның территориясендә җитештерү эшчәнлеге алып баручы юридик зат яки шәхси эшмәкәр.

2 бүлек. Гариза бирүчеләргә һәм инвестиция проектларына таләпләр

5. Конкурста сайлап алуда катнашуга эшмәкәрлек субъектлары, бер үк вакытта түбәндәге шартлар үтәлгәндә кертелә:

1) юридик зат яки шәхси эшмәкәр буларак теркәлгән һәм үз эшчәнлеген Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлгә ашыра;

2) салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы юк;

3) үзгәртеп оештыру, бетерү яки банкротлык стадиясендә тормый.

6. Конкурста сайлап алуда катнашуга түбәндәге критерийларга туры килә торган инвестиция проектлары кертелә:

1) конкурста сайлап алуда катнашучының инвестиция проекты Сәнәгать паркы территориясендә җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән булырга тиеш;

2) конкурста сайлап алуда катнашучының бизнес-планында каралган капиталь салулар күләме кимендә 20 миллион сум булырга тиеш;

3) конкурста сайлап алуда катнашучының бизнес-планы кимендә 15 эш урыны булдыруны күздә тотарга тиеш.

## 3 бүлек. Конкурс комиссиясе

7. Конкурста сайлап алу Сәнәгать паркы резидентларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) тарафыннан үткәрелә. Конкурс комиссиясе составы Башкарма комитет карары белән раслана.

8. Конкурс комиссиясе:

1) әлеге Нигезләмә таләпләренә һәм шартларына туры килүне билгеләү максатында, конкурс заявкаларын карап тикшерә;

2) конкурс заявкаларын сайлап алу йомгакларын формалаштыра һәм конкурста сайлап алуда җиңүчеләрне билгели.

9. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, комиссия әгъзаларыннан һәм секретарьдан тора.

10. Конкурс комиссиясе белән рәис җитәкчелек итә. Конкурс комиссиясе рәисе:

1) әлеге Нигезләмә нигезендә, конкурс комиссиясе эшенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

2) конкурс комиссиясе утырышын үткәрү вакытын билгели.

11. Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның функциональ вазыйфалары конкурс комиссиясе рәисе урынбасарына йөкләнә.

12. Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә илле проценты утырышта катнашкан очракта, комиссия үз функцияләрен гамәлгә ашыруга тулы хокуклы була.

13. Конкурс комиссиясе әгъзалары бурычлы:

- конкурс комиссиясе утырышларында шәхсән катнашырга һәм карарлар кабул итәргә;

- конкурста катнашучыларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итәргә;

- үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру барышында мәгълүм булган, Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында каралган мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга.

14. Секретарь тавыш бирү хокукы булмаган конкурс комиссиясе әгъзасы булып тора. Конкурс комиссиясе эшен методик һәм мәгълүмати тәэмин итүне гамәлгә ашыра, утырышлар беркетмәләрен алып бара.

15. Тавыш биргәндә конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы бер тавыш хокукына ия.

16. Конкурста сайлап алу нәтиҗәләре турында конкурс комиссиясе карары, ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашучы конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә һәм беркетмә белән раслана. Карар кабул иткәндә «риза» һәм «каршы» тавышлары саны тигез булса, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора. Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, конкурс комиссиясе рәисе урынбасарының тавышы хәлиткеч булып тора.

## 4 бүлек. Конкурс заявкаларын кабул итү һәм карап тикшерү

17. Заявкаларны кабул итү срокларын, датасын һәм урынын күрсәтеп, гаризалар кабул итү турында мәгълүмат «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарыла. Конкурс заявкаларын кабул итү чоры оештыручы тарафыннан билгеләнә һәм конкурс үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән башлап 14 эш көненнән дә ким була алмый.

18. Бер нөсхәдә кәгазь төрдәге һәм электрон йөрткечтә электрон төрдәге конкурс заявкаларын кабул итү конкурсны оештыручы тарафыннан түбәндәге адрес буенча гамәлгә ашырыла: Х.Туфан проспекты, 23, 106 кабинет. Заявка составында тапшырылган документлар гариза бирүчегә кире кайтарылмый. Эшмәкәрлек субъекты заявкада тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге өчен гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы.

19. Конкурс заявкасы түбәндәге документларны үз эченә ала:

1) гариза бирүченең җитәкчесенең имзасы белән таныкланган гариза (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта);

2) инвестиция проекты паспорты (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта);

3) инвестиция проектының бизнес-планы (әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта);

4) электрон төрдә инвестиция проектының финанс моделе;

5) инженерлык инфраструктурасына ихтыяҗның якынча исәбе (ирекле формада);

6) капиталь салулар күләменнән кимендә 30% күләмдә шәхси финанслау чыганаклары һәм заем финанслау чыганаклары булуны (аларны җәлеп итү шарты белән) раслый торган документлар;

7) гамәлгә кую документларының күчермәләре;

8) исәпләнгән салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмау турында Яр Чаллы шәһәре буенча Федераль салым хезмәте Инспекциясеннән белешмәләр.

20. Конкурс заявкасын кире кагу өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) гариза бирүче әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

2) гариза бирүченең инвестиция проекты әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

3) гариза бирүче тарафыннан тапшырылган мәгълүмат дөрес булмау;

4) заявкалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң заявка бирү;

5) әлеге Нигезләмәнең 19 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы булмаган күләмдә тапшыру.

21. Конкурс комиссиясе, конкурс үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганнан көннән башлап 20 эш көне эчендә, сайлап алуда катнашучыларның һәм алар тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәнең 5, 6 пунктларында каралган шартларга һәм критерийларга туры килүен тикшерү өчен утырышлар үткәрә, конкурста сайлап алуга кертелгән катнашучылар исемлеген формалаштыра. Конкурста сайлап алуда катнашуга кертү беркетмәсе конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан раслана.

22. Конкурста сайлап алуда катнашуга кертү беркетмәсе, түбәндәге мәгълүматларны күрсәтеп, имзаланганнан соң 3 эш көненнән дә соңга калмый, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырыла:

- конкурс заявкаларын карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

- заявкалары карап тикшерелгән конкурста сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

- аларны кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, заявкалары кире кагылган конкурста сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

- заявкалары конкурста сайлап алуга кертелгән конкурста сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат.

23. Конкурста сайлап алуны үткәрү урыны һәм вакыты турындагы мәгълүмат, конкурс комиссиясе утырышын үткәргәнче кимендә 5 эш көне алдан, катнашучылар адресына җибәрелә.

24. Конкурс заявкалары, гариза бирүче юридик затның яки гариза бирүче шәхси эшмәкәрнең җитәкчесе яисә законнар нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч язуы нигезендә аларның вәкиле катнашында, конкурста катнашуга сайлап алуга кертү беркетмәсе расланганнан соң 30 эш көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә торган конкурс комиссиясе утырышында карап тикшерелә.

25. Гариза бирүче юридик зат яки гариза бирүче шәхси эшмәкәр җитәкчесенең яисә аларның вәкиленең килүе мәҗбүри дип танылa. Алар килмәгән очракта, конкурс заявкасын карап тикшерү башкарылмый һәм Сәнәгать паркы резиденты статусын бирүдән баш тарту турында конкурс комиссиясе карары чыгарыла.

26. Заявкалар, бирү датасы нигезендә, чират тәртибендә карап тикшерелә. Проектны яклау конкурс комиссиясе алдында ачык чыгыш ясау формасында уза.

27. Тавыш бирүгә кертелгән заявкаларны карап тикшерү һәм фикер алышу нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карар чыгара:

1) Сәнәгать паркы резиденты статусы бирелә торган юридик затларны яки шәхси эшмәкәрләрне билгеләү турында;

2) Сәнәгать паркы резиденты статусы бирү кире кагылган юридик затларны яки шәхси эшмәкәрләрне билгеләү турында.

28. Конкурс комиссиясе карарлары конкурс комиссиясе секретаре алып бара торган конкурста сайлап алу беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Конкурста сайлап алу беркетмәсе конкурс комиссиясе утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, конкурс комиссиясенең катнашкан әгъзалары, конкурс заявкаларын карап тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүматны үз эченә ала. Беркетмә конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан раслана. Конкурста сайлап алуның урында уза торган этабында катнашучыларга, утырыш үткәрелгән көннән башлап 5 эш көне эчендә, Беркетмәдән өземтәләр җибәрелә.

29. Гариза бирүче конкурс комиссиясенең гамәлләренә (гамәл кылмавына) законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирү хокукына ия.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Үсеш» сәнәгать паркы
резидентларын конкурста сайлап
алуны үткәрү турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

«Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын конкурста сайлап алуда катнашу өчен гариза

| № т/б | Мәгълүматларның исемнәре | Гариза бирүченең мәгълүматлары |
|---|---|---|
| 1. | Оешманың тулы исеме | |
| 2. | Гариза бирүче - юридик затның адресы/гариза бирүче - шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, гариза бирүченең E-mail | |
| 3. | Гариза бирүченең җитәкчесенең Ф.И.А.и. (соңгысы - булган очракта) | |
| 4. | Гариза бирүченең җитәкчесенең элемтә телефон номеры | |
| 5. | Җаваплы затларның элемтә телефон номеры, Ф.И.А.и. (соңгысы - булган очракта) | |
| 7. | Конкурста сайлап алуны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итү максатларында, почта адресы, электрон почта адресы һәм элемтә телефоны | |

Җитәкче ____________________ ______________________________________
(имза) (Ф.И.А.и. (соңгысы - булган очракта)

М.У. (булган очракта)

«______» ________ 202_ ел

«Үсеш» сәнәгать паркы
резидентларын конкурста сайлап
алуны үткәрү турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

## Инвестиция проектының паспорты

| | |
|---|---|
| Проектның исеме | |
| Инициаторның исеме | |

| Инфраструктура/ресурслар төрләренә һәм куәтләргә ихтыяж | Ресурсның исеме | Барысының да куәте | Үлчәү берәмлеге | Статус (тәэмин ителгән / тәэмин ителмәгән / таләп ителми) | Техник шартлар (ТШ) алуны раслау | Ресурсларга ихтыяҗ нинди документ белән исәпләнгән |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | электр белән тәэмин итү | | МВт | | | |
| | су белән тәэмин итү: сәнәгать/хуҗалык-эчә торган (янгынга каршы) | | куб.м/ тәүлек (л/с) | | | |
| | су бүлү: сәнәгать/ хуҗалык-көнкүреш агынтылары | | куб.м/ тәүлек | | | |
| | шул исәптән янгыр сулары канализациясе * | | л/с | | | |
| | жылылык белән тәэмин итү | | Гкал/сәг | | | |
| | газ белән тәэмин итү | | $нм^3$/сәг | | | |
| | транспорт инфраструктурасы | | прив. берәмлек /тәүлек | | | |
| | элемтә челтәрләре | | -- | | | |

| Ихтыяж / чор | Үлчәү берәмлеге | 20__ | 20__ | 20_ | 20__ |
|---|---|---|---|---|---|
| электр белән тәэмин итү | МВт | | | | |
| су белән тәэмин итү: сәнәгать/хуҗалык-эчә торган, (янгынга каршы) | куб.м/ тәүлек (л/с) | | | | |
| су бүлү: сәнәгать/ хуҗалык-көнкүреш агынтылары | куб.м/ тәүлек | | | | |
| янгыр сулары канализациясе: | л/с | | | | |
| жылылык белән тәэмин итү | Гкал/сәг | | | | |
| газ белән тәэмин итү | $нм^3$/сәг | | | | |
| транспорт инфраструктурасы | привед. беәмлек/тәүлек | | | | |
| элемтә челтәрләре | -- | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Паспорт тутыру датасына торышы буенча хезмәткәрләрнең исемлектәге саны, кеше | Чор | 20__ кадәр | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | Барлыгы |
| | Саны | | | | | | |
| | | | | | | | |
| Проектның гомуми бәясе, мең сум | | | | | | | |
| Проектны финанслау графигы, мең сум | Чор | 20__ кадәр | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | Барлыгы |
| | Сумма | | | | | | |
| Акчаларын җәлеп итүгә ихтыяҗ | Сумма, мең сум | | | | | | |
| | Срок, ел | | | | | | |
| | Бурычны түләү срогын кичектерү, ел | | | | | | |
| | Инвестиция фазасында процентлар түләү чыганаклары | | | | | | |
| | Тәкъдим ителә торган тәэмин итү | Тәэмин итү төре | | | | | Базар бәясе, мең сум |
| | | | | | | | |

Кушымталар:
1. Инвестиция проекты инициаторының анкетасы ____ биттә.
2. Инвестиция проекты анкетасы ____ биттә.
3. Инвестиция проектын тормышка ашыру графигы ____ биттә .

Инвестиция проектының инициатор-компаниясе җитәкчесе

| | | |
|---|---|---|
| ________________ | ________________________ | ____________________ |
| (вазыйфасы) | (имза) | (Ф.И.А.и.) |

МУ
(булган чракта) «____» __________202_ ел

Инвестиция проекты
паспортына
1 нче кушымта

## Инвестиция проекты инициаторының
## АНКЕТАСЫ

<table>
<tr><td>Проект инициаторының исеме</td><td colspan="4"></td><td>ИНН</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td colspan="4"></td><td>ОГРН</td><td></td></tr>
<tr><td rowspan="3">Проект инициаторы турында мәгълүмат</td><td colspan="6">Юридик адресы:</td></tr>
<tr><td colspan="6">Эшчәнлек төре (ОКВЭД коды):</td></tr>
<tr><td colspan="6">Инициаторның контактлары:<br>Эшләү өчен җаваплы зат ____________ (вазыйфасы) ____________ (Ф.И.А.и.)<br>Телефон: email:</td></tr>
<tr><td>Компанияләр төркеменә каравы (аның составы)</td><td colspan="6"></td></tr>
<tr><td rowspan="13">Инициаторның милек структурасы</td><td>УКда өлеше (%)</td><td colspan="4">Компаниянең исеме/милекченең Ф.И.А.и.</td><td>ИНН</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="4"></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td colspan="4"></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td colspan="4"></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td colspan="4"></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td colspan="4"></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td colspan="4"></td><td></td></tr>
<tr><td>Күрсәткеч</td><td>20__</td><td>20__</td><td>20__</td><td>_ кв. 20_</td><td></td></tr>
<tr><td>Әйләнештән тыш активлар</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Капитал һәм резервлар</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Баланс валютасы</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Керем</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Чиста табыш</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="4">Проект инициаторы турында мәгълүмат (дөрес раслауны күрсәтергә)</td></tr>
<tr><td rowspan="4">1</td><td></td><td>Конкуренция дәрәҗәсе:</td><td></td></tr>
<tr><td>1.1.</td><td>Инициатор шактый дәрәҗәдә конкуренциядән сакланган</td><td></td></tr>
<tr><td>1.2.</td><td>Конкуренциянең типик дәрәҗәсе</td><td></td></tr>
<tr><td>1.3.</td><td>Конкуренциянең югары дәрәҗәсе</td><td></td></tr>
<tr><td rowspan="3">2</td><td rowspan="3">2.1.<br>2.2.<br>2.3.</td><td>Милекчеләр структурасының ачыклыгы</td><td></td></tr>
<tr><td>Бенефициарлар турыдан-туры төркем инициаторына/компаниясенә хуҗа була</td><td></td></tr>
<tr><td>Бенефициарларга кадәр хуҗа булуның ике дәрәҗәсеннән артмый (офшорлардан башка)</td><td></td></tr>
<tr><td rowspan="2">3</td><td rowspan="2">3.1.</td><td>Валюта куркынычлары дәрәҗәсе</td><td></td></tr>
<tr><td>Инициаторның үзкыйммәт структурасында чит ил чималы (чыгымнары) юк</td><td></td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 3.2. | *Үзкыйммәт структурасында чит ил чималы (чыгымнары) өлеше 25% тан артмый* | |
| | 3.3. | *Үзкыйммәт структурасында чит ил чималы (чыгымнары) өлеше 25% тан артып китә* | |
| 4 | | Эшлекле репутация | |
| | 4.1. | *Инициатор / инициаторның гамәлгә куючылары соңгы ел дәвамында суд тикшерүләрендә җавап бирүче булып тормады һәм булып тормый.* | |
| | 4.2. | *Инициатор/инициаторны гамәлгә куючылар соңгы ел дәвамында суд тикшерүләрендә җавап бирүчеләр булып торган яки булып тора (юридик затлар балансы валютасының соңгы хисап датасына яки гомуми еллык керемене 10% ына кадәр (физик зат һәм ИП өчен)).* | |
| | 4.3. | *Инициатор/инициаторны гамәлгә куючылар суд тикшерүләрендә җавап бирүчеләр булып тора (соңгы хисап датасына юридик зат балансының яки берләштерелгән еллык керемнең (физик затлар һәм ШЭ өчен) 10% ыннан артык).* | |
| 5 | | Салым җаваплылыгы | |
| | 5.1. | *Инициаторның Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар, процентлар һәм башка түләүләрне түләү буенча үтәлмәгән бурычы юк.* | |
| | 5.2. | *Инициаторның Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар, процентлар һәм башка түләүләрне түләү буенча үтәлмәгән бурычның гомуми күләме соңгы хисап датасына юридик затлар балансы валютасының яки физик затлар һәм ШЭ өчен еллык керемнең тулаем күләменең 10 % ыннан артык түгел.* | |
| | 5.3. | *Инициаторның Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар, процентлар һәм башка түләүләрне түләү буенча үтәлмәгән бурычның гомуми күләме соңгы хисап датасына юридик затлар балансы валютасының яки физик затлар һәм ШЭ өчен еллык керемнең тулаем күләменең 10 % ыннан артык.* | |
| 6 | | Кредит тарихы | |
| | 6.1. | *Инициатор/инициаторны гамәлгә куючылар кредит (лизинг) килешүләре буенча йөкләмәләр үтәлешен бозуга юл куймады* | |
| | 6.2. | *Инициатор/инициаторны гамәлгә куючылар кредит тарихына ия түгел/хокук бозулар моннан 3 ел элек булган.* | |
| | 6.3. | *Инициаторның/инициаторны гамәлгә куючының кредит (лизинг) килешүләре буенча срогы чыккан бурычы бар яки кредит (лизинг) килешүләре буенча соңгы 3 елда 30 көннән артык дәвамлылыкта йөкләмәләр бозылган* | |
| 7 | | Тармакта эшләү/инвестиция проектларын тормышка ашыру тәҗрибәсе булу | |
| | 7.1. | *Өлеше кимендә 25 процент тәшкил иткән инициаторны гамәлгә куючыларының берсенең яки инициатор җитәкчесенең проект карый торган тармакта 5 елдан ким булмаган эш тәҗрибәсе бар.* | |
| | 7.2. | *Өлеше кимендә 25 процент тәшкил иткән инициаторны гамәлгә куючыларының берсенең яки инициатор җитәкчесенең проект карый торган тармакта 3 елдан ким булмаган эш тәҗрибәсе бар.* | |
| | 7.3. | *Өлеше кимендә 25 процент тәшкил иткән инициаторны гамәлгә куючыларының берсенең дә һәм инициатор җитәкчесенең проект карый торган тармакта эш тәҗрибәсе, инвестиция проектларын тормышка ашыру тәҗрибәсе юк* | |
| 8 | | Гадәттән тыш хәлләр (аварияләр, янгыннар, һәлакәтләр һәм башкалар) | |
| | 8.1. | *Инциаторның/инициаторны гамәлгә куючыларның үз эшчәнлекләре чорында гадәттән тыш хәлләр теркәлмәгән* | |
| | 8.2. | *Инициаторда/инициаторны гамәлгә куючыларда гадәттән тыш хәл булуга 3 елдан артык вакыт узган* | |
| | 8.3. | *Инициаторда/инициаторны гамәлгә куючыларда гадәттән тыш хәл булуга 3 елдан ким вакыт узган* | |
| 9 | | Инициаторга/компанияләр төркеменә һәм/яки аларның проектларына дәүләт хакимияте органнары дәрәҗәсендә ярдәм | |
| | 9.1. | *Инциаторның проекты регионның өстенлекле проектлары исемлегенә кертелгән яки инициатор/компанияләр төркеме бюджет субсидияләрен алучы булып тора* | |
| | 9.2. | *Дәүләт хакимияте органнарының грамоталары, дипломнары яки рәхмәт хатлары бар* | |
| | 9.3. | *Инициаторга/компанияләр төркеменә һәм/яки аларның проектларына дәүләт хакимияте органнары дәрәҗәсендә ярдәм юк* | |
| 10 | | Фактта түләнә торган салымнар күләме | |
| | 10.1. | *Төркем әгъзаларының берсе Федерация Субъектының иң эре салым түләүчеләрнең беренче йөзлегенә керә* | |
| | 10.2. | *Төркем әгъзаларының берсе Федерация Субъектының иң эре салым түләүчеләренең беренче меңлегенә керә* | |
| | 10.3. | *Төркем әгъзаларының берәрсе Федерация Субъектыннан иң эре салым түләүчеләрнең беренче меңлегенә кермәү турында мәгълүмат алынмаган* | |
| 11 | | Аудитор бәяләмәсе булу | |
| | 11.1. | *Бар, житди кимчелекләрсез /Таләп ителми* | |
| | 11.2. | *Бар, житди кимчелекләр белән/Аудитны үткәрү бурычы булгнда - юк.* | |

| | | |
|---|---|---|
| Инициаторның һәм компанияләр төркеменең финанс хәле турында мәгълүмат, мең сумнарда | | |
| *12* | Компанияләр төркеме капиталы (әгәр төркем булмаса, күрсәтелми)<br>Төркем капиталын исәпләү өчен төркемнең үз капиталын берләштерелгән идарә исәбен алу мәгълүматлары кабул ителә | |
| *13* | Хисап елында компанияләр төркеменең берләштерелгән табышы (әгәр төркем булмаса, күрсәтелми) | |
| *14* | Хисап елында компанияләр төркеменең берләштерелгән чиста табышы (әгәр төркем булмаса, күрсәтелми) | |
| *15* | Хисап елында компанияләр төркеменең исәпләп чыгарылган амортизациясе (әгәр төркем булмаса, *инициаторның*) | |
| *16* | Төп бурычны план буенча түләү проектны тормышка ашыру чорында планлаштырылган банклар /финанс оешмалары алдында компанияләр төркеме (әгәр төркем булмаса, инициатор) йөкләмәләренең гамәлдәге кредитлары/лимитлары күләме | |

*Барлык исәпләүләр соңгы хисап чорына бухгалтерлык (финанс) хисабы нигезендә башкарыла*

Инвестиция проектының инициатор-компаниясе җитәкчесе

| ______________________ | ______________________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (вазыйфасы) | (имза) | (Ф.И.А.и.) |

МУ (булган очракта) «____» ___________202_ ел

Инвестиция проекты
паспортына
2 нче кушымта

# Инвестиция проекты АНКЕТАСЫ

| | | | |
|---|---|---|---|
| Яңа инвестиция проектының исеме | | Проект тибы | |
| Проектны тормышка ашыру урыны | | Проект стадиясе | |

| Җир участокларына хокукларны рәсмиләштерү | т/б | ҖУ кадастр номеры | Мәйданы (Га) | Хокукларны рәсмиләштерү | Аренда срогы |
|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | | | | |
| | 2 | | | | |
| | 3 | | | | |
| | 4 | | | | |
| | 5 | | | | |

| Инвестиция проектын тормышка ашыру кысаларында проект-смета документлары | ПСД һәм ГЭ кирәклеге | ПСД һәм ГЭ эшләү (алу) статусы | ПСД эшләүне төгәлләү һәм ГЭ алу датасы (әгәр кулланылса) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

| Чыгымнар структурасы | Чыгымнар статьясы | Бәясе, мең сум |
|---|---|---|
| | Җиһаз сатып алу | |
| | СМР | |
| | Әйләнештәге акчалар | |
| | Башкалар | |

| Проект буенча башкарылган чыгымнарны финанслау, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Проект буенча башкарылган барлык чыгымнар, шул исәптән | | | |
| | Үз акчалары хисабына финанслау суммасы | | | |
| | Үз акчаларының чыганагы | | | |
| | Заем (җәлеп ителгән) акчалары хисабына финанслау суммасы | | | |
| | Заем акчалары чыганагы | | | |
| | Заем акчаларын бирү шартлары | Срок, ел | Ставка, % | Искәрмәләр |
| | | | | |

<table>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td rowspan="2"></td><td>Күрсәткеч</td><td>Үлчәү берәмлеге</td><td colspan="2">Зурлыгы</td></tr>
<tr><td>Фараз чоры срогы</td><td>ел</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td rowspan="5">Проект нәтиҗәлелегенең фаразланган күрсәткечләре (инфрастуктура объектлары куәтләрен уникаль кулланучы булып торган инвестиция проекты өчен мәҗбүри)</td><td>NPV (терминаль бәяне исәпкә алмыйча)</td><td>мең сум</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td>IRR</td><td>%</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td>Фаразланган керем</td><td>мең сум</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td>Фаразланган EBITDA</td><td>мең сум</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td>Чыгымнар каплану срогы</td><td>ел</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td rowspan="3">Инвестиция проектының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Монопрофильле муниципаль берәмлекләрне үстерү проектларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан «ВЭБ.РФ» дәүләт корпорациясенә Россия Федерациясенең мөлкәт взносы рәвешендә субсидия бирү кагыйдәләрен раслау турында һәм «ВЭБ.РФ» дәүләт корпорациясенең финанс сәясәте турында Меморандумга үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 28 декабрендәге 2517 номерлы Карары таләпләренә туры килүе</td><td></td><td colspan="3">Проект моношәһәрнең шәһәр төзүче оешмасын реконструкцияләү, техник яктан яңадан җиһазландыру, модернизацияләү һәм (яки) өстәмә җиһазландыру буенча инвестиция проекты булып тормый</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="3">Моношәһәрнең шәһәр төзүче оешмасыннан сатып алына торган товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) еллык бәясе инвестиция проектын тормышка ашыру максатларында сатып алына торган барлык товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) еллык бәясенең 50 процентыннан артмый</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="3">Моношәһәрнең шәһәр төзүче оешмасының товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләрне) сатудан еллык кереме инвестиция проектын тормышка ашыру нәтиҗәсендә житештерелгән (башкарылган, күрсәтелгән) товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатудан алына торган еллык керемнең 50 процентыннан артмый.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="4">Инвестиция проекты турында мәгълүмат (дөрес раслауны күрсәтергә)</td></tr>
<tr><td rowspan="4">1</td><td></td><td>Проектның характеристикасы</td><td></td></tr>
<tr><td>1.1.</td><td>Россия Федерациясе территориясендә уникаль проект (чыгарыла торган продукциянең аналоглары юк/технологиянең аналоглары юк)</td><td></td></tr>
<tr><td>1.2.</td><td>Россия Федерациясе территориясендә проектның аналоглары бар (чыгарыла торган продукция житештерелә/житештерү технологиясенең аналоглары бар)</td><td></td></tr>
<tr><td>1.3.</td><td>Производствоны реконструкцияләү/техник яктан яңадан җиһазландыру/модернизацияләү һәм/яки җиһазландырып бетерү</td><td></td></tr>
<tr><td rowspan="4">2</td><td></td><td>Җитештерү мәйданчыгы булу</td><td></td></tr>
<tr><td>2.1.</td><td>Мәйданчык милектә, сроксыз файдалануда яки озак сроклы арендада тора</td><td></td></tr>
<tr><td>2.2.</td><td>Мәйданчыкны 12 айдан кимрәк арендалау шартнамәсе төзелгән</td><td></td></tr>
<tr><td>2.3.</td><td>Җитештерү мәйданчыгын урнаштыруны күздә тоту билгеләнгән</td><td></td></tr>
<tr><td rowspan="2">3</td><td></td><td>Инициаторның үз акчалары булу</td><td></td></tr>
<tr><td>3.1.</td><td>Инициаторның (заемга бирүче - инициатор катнашучысының, төркемдә катнашучының) исәп-хисап счетларында/депозитларында акчалар булу белән раслана</td><td></td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 3.2. | *Инициаторның (заемга бирүче – инициатор катнашучысының, төркемдә катнашучыларның) агымдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре белән раслана* | |
| | 3.3. | *Проект буенча элек башкарылган чыгымнар раслана* | |
| | 3.4. | *Башкалар (раслаучы документларны теркәп)* | |
| | 3.5. | *Үз акчалары юк / проекттан булачак табыш хисабына кертеләчәк* | |
| 4 | | Заем акчалары чыганакларын раслау (ВЭБ.РФ акчаларыннан тыш) | |
| | 4.1. | *Проект ихтыяжларына туры килә торган шартнамә төзелгән, финанслау башарыла/заем финанславы таләп ителми* | |
| | 4.2. | *Аерым шартлары булган шартнамә төзелгән, финанслау алып барылмый яки туктатылган* | |
| | 4.3. | *Финанслау шартлары турында заем бирүченең карары алынган, шартнамә төзелмәгән* | |
| | 4.4. | *Финанслауга гариза карала, карар алынмаган* | |
| 5 | | Проект продукциясен/хезмәтләр күрсәтүне сатып алучылар | |
| | 5.1. | *Елдан артык төп сатып алучылар белән хезмәттәшлек тәҗрибәсе* | |
| | 5.2. | *Төп сатып алучылар белән шартнамәләр төзелгән* | |
| | 5.3. | *Төп сатып алучылар билгеләнгән, хезмәттәшлек турында килешү бар* | |
| | 5.4. | *Төп сатып алучылар проектны тормышка ашырганда билгеләнәчәк* | |
| 6 | | Сатып алучыларга бәйлелек дәрәҗәсе | |
| | 6.1. | *Контрагентларның югары диверсификациясе аркасында төп сатып алучылар җиңел алыштырыла яки юк.* | |
| | 6.2. | *Төп сатып алучылар өлешенә 30% тан да артмаган күләмдә туры килә* | |
| | 6.3. | *Алар белән үзара мөнәсәбәтләрне югалту авыр тулыландырыла торган төп сатып алучылар (30 проценттан артык өлеше булган) бар* | |
| 7 | | Чимал/материаллар белән тәэмин итүчеләр | |
| | 7.1. | *Елдан артык төп тәэмин итүчеләр белән хезмәттәшлек тәҗрибәсе, гамәлдәге шартнамәләр бар* | |
| | 7.2. | *Төп тәэмин итүчеләр белән шартнамәләр төзелгән* | |
| | 7.3. | *Төп тәэмин итүчеләр билгеләнгән, хезмәттәшлек турында килешүләр/тәкъдимнәр бар* | |
| | 7.4. | *Төп тәэмин итүчеләр проектны тормышка ашырганда билгеләнәчәк* | |
| 8 | | Тәэмин итүчеләргә бәйлелек дәрәҗәсе | |
| | 8.1. | *Контрагентларның югары диверсификациясе аркасында төп тәэмин итүчеләр җиңел алыштырыла яки юк* | |
| | 8.2. | *Төп тәэмин итүчеләр өлешенә 30%тан да артык күләмдә туры килә.* | |
| | 8.3. | *Алар белән үзара мөнәсәбәтләрне югалту авыр тулыландырыла торган төп сатып алучылар (30 проценттан артык өлеше булган) бар* | |
| 9 | | Базарда маркетинг тикшеренүе | |
| | 9.1. | *Маркетинг тикшеренүе бәйсез экспертны җәлеп итеп үткәрелгән* | |
| | 9.2. | *Маркетинг тикшеренүе инициаторның үз көче белән үткәрелгән* | |
| | 9.3. | *Маркетинг тикшеренүе үткәрелмәгән* | |
| 10 | | Бизнес-план булу | |
| | 10.1. | *Бизнес-план әзерләнгән* | |
| | 10.2. | *Бизнес-план эшләү стадиясендә, эш версиясе бар* | |
| | 10.3. | *Бизнес-план юк* | |
| 11 | | Финанс моделе булу | |
| | 11.1. | *Финанс моделе әзерләнгән* | |
| | 11.2. | *Финанс моделе эшләү стадиясендә, эш версиясе бар* | |
| | 11.3. | *Финанс моделе юк* | |
| 12 | | ПСД булу | |
| | 12.1. | *ПСД әзерләнгән яки законнар нигезендә таләп ителми* | |
| | 12.2. | *ПСД эшләү стадиясендә, ПСД эшләүгә шартнамә төзелгән* | |
| | 12.3. | *ПСД юк* | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13 | | ПСДга экспертиза үткәрү | |
| | *13.1.* | *ПСДга экспертиза үткәрелгән яки законнар нигезендә таләп ителми* | |
| | *13.2.* | *ПСДга экспертиза үткәрелә, ПСД үткәрү өчен шартнамә төзелгән* | |
| | *13.3.* | *ПСДга экспертиза үткәрелмәгән* | |

Инвестиция проектының инициатор-компаниясе житәкчесе

_______________ _______________ ______________________________

(вазыйфасы) (имза) (Ф.И.А.и.)

МУ (булган очракта) «___» ___________ 202 ел

Инвестиция проекты
паспортына
3 нче кушымта

## Инвестиция проектын тормышка ашыру графигы

«________________________________________»

*(Инвестиция алды стадиясеннән башлап җитештерүнең проектлана торган тулы куәтенә чыгуына кадәр этаплар буенча расшифровкалау)*

*(Проектны тормышка ашыруның һәр стадиясенең чоры ячейкада (ларда) төсле буяу белән тутырыла)*

| Проектны тормышка ашыру стадияләре | $T_1$ | $T_1^1$ | ... | ... | ... | ... | ... | ... | ... | $T_n^1$ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Проектны тормышка ашыру өчен җир участогы алу | | | | | | | | | | |
| Технологик тоташтыруга техник шартлар алу | | | | | | | | | | |
| Инженерлык тикшеренүләре үткәрү | | | | | | | | | | |
| Инвестиция проекты объектлары буенча проект-смета документларын эшләү һәм дәүләт (дәүләтнеке булмаган) экспертизасы бәяләмәсен алу *(кирәк булганда)* | | | | | | | | | | |
| Банктан финанслауның беренчел шартларын алу, соинвестор белән проектны финанслау турында алдан килешүне имзалау | | | | | | | | | | |
| *Кредит килешүе (заем финанславын, соинвесторлар акчаларын җәлеп итүне тәэмин итә торган башка документ) төзү* | | | | | | | | | | |
| Инвестиция проекты кысаларында объектлар төзелешенә һәм төзү-монтажлау эшләрен гамәлгә ашыруга генераль подряд шартнамәсен (булган очракта) имзалау | | | | | | | | | | |
| Җиһаз сатып алуга, аны кайтаруга, урнаштыруга, эшләтеп җибәрүгә шартнамәне (контрактны) имзалау | | | | | | | | | | |
| Технологик тоташтыруның планлаштырылган датасы (проектны тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктураның барлык төрләре буенча технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру срогы күрсәтелә) | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *электр белән тәэмин итү* | | | | | | | | | | |
| *су белән тәэмин итү* | | | | | | | | | | |
| *су бүлү* | | | | | | | | | | |
| *шул исәптән яңгыр сулары канализациясе* | | | | | | | | | | |
| *җылылык белән тәэмин итү* | | | | | | | | | | |
| *газ белән тәэмин итү* | | | | | | | | | | |
| *элемтә челтәрләре* | | | | | | | | | | |
| *транспорт инфраструктурасы (кирәкле транспорт объектларын эксплуатациягә тапшыру)* | | | | | | | | | | |
| Инвестиция проекты объектларын эксплуатациягә тапшыру (кирәк булганда, этапларга аеруны күрсәтеп) | | | | | | | | | | |
| Продукцияне чыгара башлау | | | | | | | | | | |
| *Инвестиция проектын тормышка ашыру барышында башка төп вакыйгалар (контрагентлар белән контрактлар төзү, проектны тормышка ашыруга бәйле норматив актларны раслау һ.б.)* | | | | | | | | | | |
| *Төп вакыйга 1* | | | | | | | | | | |
| *Төп вакыйга n* | | | | | | | | | | |

1 – календарь ел кварталы
2 – проектны тормышка ашыру спецификасына карап, аерым стадияләр үзгәртелергә/төшереп калдырылырга/өстәмәләр кертелергә мөмкин

Инвестиция проектының инициатор-компаниясе җитәкчесе

_________________________ (вазыйфасы) _______________ (имза) _________________________ (Ф.И.А.и.)

МУ (булган очракта) «__» _______ 202_ ел

«Үсеш» сәнәгать паркы
резидентларын конкурс
нигезендә сайлап алуны
үткәрү турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

«Үсеш» сәнәгать паркы резиденты стасусы алу өчен
инвестиция проектының
БИЗНЕС-ПЛАНЫ

1. Проектның инициаторы

1.1. Юридик затның – «Үсеш» сәнәгать паркы резидентының (алга таба – претендент) исеме.

1.2. Претендентның оештыру-хокукый формасы, учредительләрнең исеме һәм адресы.

1.3. Претендентның теркәлү датасы, теркәү таныклыгының номеры.

1.4. Претендентның дәүләти теркәлү урыны һәм почта адресы.

1.5. Претендент җитәкчеләренең Ф.И.А.и., телефон номерлары.

1.6. Предприятиенең икътисадый эшчәнлеге төрләре.

1.7. Проектны тормышка ашыру срогы.

1.8. Проектны тормышка ашыруның тулаем бәясе, көтелəчәк акча чыганаклары һәм аларның структурасы (претендентның шәхси һәм заем акчалары, бюджеттан финанслау).

2. Проектның резюмесы

2.1. Фаразланган проектның асылы.

2.2. Проектны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге.

Чыгым капланунын гади срогы;

Чыгым капланунын дисконт ясалган срогы;

NPV – агымдагы чиста бәя;

IRR – эчке рентабельлек нормасы.

2.3. Проектның гомуми бәясе.

2.4. Зарури финанс ресурслары.

2.5. Проектны тормышка ашыру нәтиҗәсе

Социаль нәтиҗә (булдырыла торган эш урыннары);

Экологик нәтиҗә;

Икътисадый нәтиҗә (барлык дәрәҗә бюджетларга салым керемнәренең күләме).

3. Тармактагы эшләр торышына анализ

3.1. Тармакның хәзерге торышына һәм үсеш перспективаларына анализ.

3.2. Тармак производствосында претендентның көтеләчәк өлеше.

(Яр Чаллы шәһәренең икътисадый һәм социаль үсеше өчен әлеге производствоның әһәмияте).

3.3. Төп (потенциаль) конкурентлар исемлеге, аларның базардагы өлеше.

3.4. Фаразланган бизнесның гомуми концепциясе.

4. Продукциягә (эшләргә, хезмәтләргә) тасвирлама

4.1. Продукциянең (эшләрнең, хезмәтләрнең) төп төрләре, аларның характеристикалары.

4.2. Претендентның әлеге продукцияне (эшләрне, хезмәтләрне) җитештерү тәҗрибәсе булу.

4.3. Продукциянең (эшләрнең, хезмәтләрнең) аналогик һәм конкуренцияле (алмаштыра торган) төрләренең төп характеристикаларына чагыштырма анализ.

5. Продукция (эшләр, хезмәтләр) маркетингы һәм сату

5.1. Продукция (эшләр, хезмәтләр) сату базарларына анализ.

5.2. Претендентның базардагы өлешенә бәя.

5.3. Претендент маркетингының гомуми стратегиясе.

5.4. Претендентның бәя кую характеристикасы

5.5. Продукцияне (эшләрне, хезмәтләрне) реализацияләү тактикасы. Реализацияләү методларына анализ (турыдан-туры кайтару, сәүдә вәкилләре, арадашчылар) һәм аларның нәтиҗәлелеге, озак сроклы перспективада өстенлекле сату каналларын сайлау, кайтару ниятенең килешүләре һәм беркетмәләре булу.

5.6. Сатылганнан соң хезмәт күрсәтү һәм гарантияләр бирү сәясәте.

5.7. Продукциягә (эшләргә, хезмәтләргә) реклама һәм аны базарга кертеп җибәрү.

5.8. Сыйфат өлкәсендә стратегия.

6. Производство планы

6.1. Проектны тормышка ашыру урыны.

(Транспорт, инженерлык, социаль инфраструктура белән тәэмин ителеш; төзү-монтажлау һәм өстәмә ремонт оешмалары булу; производство мәйданнарының булуы һәм торышы).

6.2. Проект буенча эшләрне планлаштыру һәм аларның смета бәясе (төзү, монтажлау, файдалануга тапшыру һәм җиһазның проекттагы куәтенә ирешү сроклары – һәр этапны тормышка ашыруга чыгымнар күрсәтелгән календарь план).

6.3. Номенклатурадан чыгып, претендентның производство программасы.

6.4. Производство егәрлеге һәм аны үстерү.

6.5. Капиталь туплаулар планы.

6.6. Материаль-техник тәэминат планы (материаль ресурсларга ихтыяҗлык исәбе, ресурсларны кайтаручылар, кайтару шартлары, якынча бәяләр, ресурслар белән тәэмин итүнең ихтимал альтернатив чыганаклары).

6.7. Хезмәт ресурслары.

6.8. Проектны тормышка ашыруның экологик нәтиҗәләренә характеристика, экологик һәм техник куркынычсызлыкны тәэмин итү).

6.9. Продукция (эшләр, хезмәтләр) сыйфаты системасына анализ.

7. Оештыру планы

7.1. Претендентның югары җитәкчелегенә һәм милекчеләргә кыскача характеристика.

7.2. Оешма-претендент идарәсенең оештыру структурасы.

7.3. Бизнесны үстерүдә төп чараларның план-графигы.

7.4. Гамәлдәге (потенциаль) стратегик партнерлар һәм контрагентлар исемлеге.

8. Финанс планы

8.1. Кабул ителгән фаразлар.

8.2. Реализацияләүдән табыш.

8.3. Агымдагы чыгымнар.

8.3.1. Турыдан-туры материаль чыгымнар;

8.3.2. Хезмәткә түләү өчен турыдан-туры чыгымнар;

8.3.3. Турыдан-туры булмаган чыгымнар.

8.4. Финанслау чыганаклары.

8.5. Табыш һәм зыян турында хисап.

8.6. Акча хәрәкәте турында хисап.

8.7. Проект нәтиҗәлелегенең күрсәткечләре.

8.8. Проектны тормышка ашыру куркынычына анализ. Сизгерлеккә анализ.

Башкарма комитетның
2024 елның 19 апрелендәге
2474 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе составы

| № т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Салахов Фәрид Шавкат улы | конкурс комиссиясе рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2. | Кропотова Наталия Анатольевна | конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 3. | Пучкин Константин Юрьевич | конкурс комиссиясе секретаре, «Үсеш» сәнәгать паркы» ИК директоры (килешү буенча) |
| конкурс комиссиясе әгъзалары: | | |
| 4. | Бәшәров Фәрид Рәшид улы | «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлегенең генераль директоры (килешү буенча) |
| 5. | Гыйләҗева Гүзәл Вәлиәхмәт кызы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы |
| 6. | Зәйнетдинов Гадел Марсель улы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы урынбасары, эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү бүлеге башлыгы |
| 7. | Лашин Алексей Николаевич | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы |
| 8. | Миңнегалиев Раил Габделхәй улы | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты (килешү буенча) |
| 9. | Фришко Ирина Александровна | «Альфа-Банк» АҖнең Татарстан Республикасы буенча корпоратив клиентларны үстерү буенча директоры (килешү буенча). |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева